УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан ш.

2017 елның "12" октябре № 66

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү тәртибен раслау турында

"Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәргәндә бердәм ысул тәэмин итү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Шушы боерык кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Мәгълүмат ресурслары секторына күрсәтелгән Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенә (алга таба – Идарә) килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә ярты елга бер мәртәбә анализ үткәрергә һәм Идарәгә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализны ярты елга бер мәртәбә Идарәнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү тәртибен раслау турында" 2015 елның 14 июлендәге 49 номерлы боерыгының көчен югалтуын танырга.
4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Идарә башлыгы** **А.Р.Шәвәлиева**

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
ГХАТ идарәсенең
12.10.2017 № 66 боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү тәртибе (алга таба – Тәртип) "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенә (алга таба – Идарә) килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәргәндә бердәм ысул тәэмин итү максатларында эшләнде.

1.2. Бу Тәртиптә Идарәгә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрүнең критерийлары һәм шартлары билгеләнә.

## II. Идарәгә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү тәртибе

2.1. Идарәгә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ярты ел һәм узып киткән ел йомгаклары буенча мәгълүмат ресурслары секторы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Гражданнарның Идарәгә килгән мөрәҗәгатьләренә үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча хисап чоры өчен Идарәгә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ турында хисап (алга таба – Хисап) рәсмиләштерелә.

2.2. Хисап мәгълүмат ресурслары бүлеге тарафыннан "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Идарәнең рәсми сайтындагы "Гражданнарның мөрәҗәгатьләре һәм аларны кабул итү" бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 нче көненә кадәр урнаштырыла.

2.3. Хисапта түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

килгән, башка адресларга җибәрелгән һәм каралган язмача мөрәҗәгатьләр саны;

электрон документ рәвешендә килгән мөрәҗәгатьләр саны;

гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм вакыты;

шәхсән кабул ителгән гражданнар саны;

гражданнарны шәхсән кабул итү вәкаләте бирелгән затлар;

вәкаләтле затлар тарафыннан урынга чыгып башкарылган кабул итүләр саны;

мөрәҗәгатьләрнең тематикасы;

мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм бүтән актлар (булган очракта) турында мәгълүмат.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Шушы Тәртипкә карата барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Идарә башлыгы тарафыннан раслана.

---